| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.07.2019 г.Казань № 135/2-пр

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне раслау турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервларына кертүгә конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы һәм 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» Указы нигезендә **БОЕРАМ:**

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы нигезләмәне upасларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары Н.Л.Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары - министр М.Г. Әхмәтов

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 01.07.2019 № 135/2-пр боерыгы белән расланды

# Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре аппаратларында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясе (алга таба - конкурс комиссиясе) составы, аның сроклары һәм эш тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында (алга таба - Министрлык) дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс (алга таба - конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт хезмәтенә бертигез керүгә конституциячел хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба - граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итә.

1.2. Министрлыкта конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы (алга таба - Федеральный закон), Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервларына кертүгә конкурслар уздыруның бердәм методикасын раслау турында» 2018 елның 31 мартындагы 397 номерлы карары, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә кадрлар резервы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 елның 14 мартындагы ПУ-127 номерлы Указы һәм 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан

хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» Указы нигезендә уздырыла.

Конкурс кандидатларның дәүләт граждан хезмәте (алга таба - граждан хезмәте) вазыйфасын биләүгә һөнәри дәрәҗәсен, граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен аларның квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс Федераль закон нигезендә конкурс буенча биләнә торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (аның вазыйфаларын башкаручы) (алга таба - министр) карары буенча игълан ителә.

1.4. Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын һәм Министрлыкның булган кадрлар резервын биләү өчен Министрлыкның белгечләргә ихтыяҗын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча кадрлар бүлеге тарафыннан оештырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертүгә конкурс әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан уздырыла.

1.5. Конкурс түбәндәге максатларда уздырыла:

Россия Федерациясе гражданнарының дәүләт граждан хезмәтенә аларның сәләте һәм һөнәри әзерлеге нигезендә бертигез керүгә конституциячел хокукын, шулай ук граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукын тәэмин итү өчен;

федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән барлык кандидатлар арасыннан граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә аеруча туры килә торган кандидатларны сайлап алу өчен;

граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен Министрлыкның кадрлар резервын булдыру максатында.

1.6. Конкурслар уздырганда хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен алар конкурс биремнәрен һәм процедураларын башкарганда бертигез шартлар тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмиятле критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән конкурста катнашучылар арасында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларының тиешле таләпләренә туры килә торган затларны билгеләү (кадрлар резервына кертү).

1.7. Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс түбәндәге очракларда уздырылмый:

“җитәкчеләр” һәм “ярдәмчеләр (киңәшчеләр)” категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфасына билгеле бер срокка вәкаләтләр биләүгә билгеләгәндә;

вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә

һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда граждан хезмәткәрен башка граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куйганда;

граждан хезмәтендә ккадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп куйганда.

1.8. Министрлыкта вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс түбәндәге очракларда уздырылмаска мөмкин:

вазыйфаи бурычларны үтәү Министрлык боерыгы белән раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләргә бәйле аерым граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләп куйганда;

граждан хезмәтенең министр карары буенча кече граждан хезмәте вазыйфалары төркеменә керә торган вазыйфаларына билгеләп куйганда.

1.9. Кандидат Россия Федерациясе законнары нигезендә конкурс комиссиясе карарына шикаять бирергә хокуклы.

1.10. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуга кертелмәгән дәгъвачыларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары конкурс тәмамланганнан соң өч көн эчендә язмача гариза буенча кайтарыла. Бу срок узганчы документлар Министрлыкның кадрлар бүлегендә саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш. Конкурста катнашу өчен электрон рәвештә тапшырылган документлар өч ел дәвамында саклана, шуннан соң аннан алынырга тиеш.

1.11. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс уздыру урынына бару һәм аннан кайту, торак урыны яллау, яшәү, элемтә чараларыннан файдалану һәм башкалар) кандидатларның үз акчаларыннан тотыла.

## II. Конкурс комиссиясен төзү һәм аның эш тәртибе

2.1. Конкурслар уздыру өчен Министрлыкта министр боерыгы белән Министрлык аппараты өчен һәм Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының муниципаль районнардагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре аппаратлары өчен даими эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Комиссия составы министр боерыгы белән раслана.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, секретарьдан һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.3. Конкурс комиссиясенең эшчәнлегенә комиссия рәисе җитәкчелек итә. Комиссия рәисе булмаганда, аның хокукларын һәм бурычларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе секретаре комиссия эшен тәэмин итә (гаризалар алу, эшнамәләр ачу, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү).

2.4. Конкурс комиссиясе составына министрның беренче урынбасары һәм (яисә) ул вәкаләт биргән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән кадрлар бүлегеннән, Министрлыкның юридик мәсьәләләр секторыннан), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук министр таләбе буенча граждан хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча

бәйсез эксперт-белгечләр буларак (экспертларның шәхси белешмәләре күрсәтелмичә) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакырыла торган фән, мәгариф һәм башка оешмалар вәкилләре керә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан дүрттән береннән ким булмый.

Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан дүрттән береннән ким булмый.

2.5. Граждан хезмәтенең дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрне куллануга бәйле вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру өчен конкурс комиссиясе составы дәүләт сере турында Россия Федерациясе законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга тәэсир итәрлек конфликтлар барлыкка килү мөмкинлеген булдырмый торган итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына керү өчен) кимендә ике кандидат булганда уздырыла һәм анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, вәкаләтле санала. Граждан хезмәте вазыйфасын биләүче әгъзалар катнашында гына конкурс комиссиясе утырышын уздыру рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе тарафыннан кандидат белән кара-каршы әңгәмә алып бармыйча гына конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул итү рөхсәт ителми.

2.9. Конкурс комиссиясенең карары кандидаттан башка кабул ителә.

Конкурс уздыру нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары аның утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш биреп кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

2.10. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс йомгаклары буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча конкурс комиссиясе карары итеп рәсмиләштерелә. Кадрлар резервына кертүгә конкурс йомгаклары буенча комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча конкурс комиссиясе утурышы беркетмәсе итеп рәсмиләштерелә.

Күрсәтелгән карарда һәм беркетмәдә кандидатларның рейтингы билгеләнә, шунда ук җыелган баллар һәм конкурс комиссиясе бәяләве нәтиҗәләре буенча алар алган урыннар күрсәтелә.

2.11. Конкурс уздыруны һәм конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыруны һәм тәэмин итүне Министрлыкның кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## III. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурста катнашуга Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы

вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү) өчен квалификация таләпләренә туры килә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документларны бу Нигезләмәнең 3.7 пунктында каралган срокка тапшырган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба - гражданнар), шулай ук граждан хезмәткәрләре кертелә.

3.2. Граждан (граждан хезмәткәре) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертү өчен) квалификация таләпләренә туры килмәү сәбәпле, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә, конкурста катнашуга кертелми.

3.3. Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатларга таләпләр дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.4. Конкурста катнашуга теләк белдергән граждан Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта нигезендәге форма буенча шәхси гариза;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча тутырылган һәм имзаланган анкета, фотография белән;

паспортының яисә аны алыштыручы документының күчермәсен (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән тапшырыла);

кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

нотариаль яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган хезмәт кенәгәсе күчермәсе (гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеге беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш) яки гражданның эш (хезмәт) эшчәнлеген раслый торган башка документлар;

белем һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук граждан теләге белән өстәмә һөнәри белем нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яисә бирүне раслый торган документлар күчермәләре, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирү турында документлар күчермәләре, алар нотариаль яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган булырга тиеш;

гражданның граждан хезмәтенә керүенә яисә аны узуга тоткарлык тудырмый торган авыруы булмавы турында документ (Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган исәпкә алу формасы 001-ГС/у);

Федераль законда, башка федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

3.5. Министрлыкта конкурста катнашуга теләк белдергән граждан хезмәте вазыйфасын биләүче граждан хезмәткәре министр исеменә гариза бирә.

Башка дәүләт органында граждан хезмәте вазыйфасын биләгән һәм конкурста катнашуга теләк белдергән граждан хезмәткәре Министрлыкка министр исеменә

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган форма буенча, фотография белән, анкета тапшыра, ул граждан хезмәте вазыйфасын биләгән дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан имзаланган һәм таныкланган булырга тиеш.

3.6. Гражданның (граждан хезмәткәренең) теләге белән аны дәүләт серен яисә закон белән саклана торган серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга кертү процедурасын рәсмиләштерү башкарыла, бу граждан (граждан хезмәткәре) урнашуга дәгъва кыла торган граждан хезмәте вазыйфасы буенча бурычларны башкару шундый белешмәләрдән файдалануга бәйле булган очракта башкарыла.

Граждан тарафыннан министр исеменә тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш. Электрон рәвештә тапшырылган белешмәләр автоматлаштырылган рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә тикшерелә.

3.7. Әлеге Нигезләмәнең 3.4 һәм 3.5 пунктларында күрсәтелгән документлар аларны «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составына идарә итүнең бердәм мәгълүмати системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының (алга таба – Федераль мәгълүмат системасы) рәсми сайтында кабул итү турында белдерү урнаштырылган көннән 21 календарь көн эчендә Министрлыкка гражданның (граждан хезмәткәренең) шәхсән үзе тарафыннан тапшырыла, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат системасыннан файдаланып, почта аша яисә электрон рәвештә җибәрелә.

Документларны мөһим сәбәпсез вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә яисә кагыйдәләрне бозып тапшыру гражданга (граждан хезмәткәренә) аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез була.

Документларны мөһим сәбәп аркасында вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә яисә кагыйдәләрне бозып тапшырганда министр аларны кабул итү срокларын күчерергә хокуклы.

## IV. Конкурсны уздыру методикасы

4.1. Конкурсны уздыруга әзерләнү кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларын (алга таба - бәяләү ысуллары) сайлауны һәм граждан хезмәтенең биләүгә конкурслар игълан итү планлаштырыла торган вакантлы вазыйфасына карата граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары нигезләмәләрен актуальләштерү зарурлыгы булганда, аларга тиешле конкурс биремнәре әзерләүне күздә тота.

4.2. Граждан хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентлары нигезләмәләрен актуальләштерүне, бәяләү ысулларын сайлауны һәм аларга тиешле конкурс биремнәре әзерләүне, кадрлар бүлеге белән килештереп, Министрлыкның кызыксынучы бүлекчәсе гамәлгә ашыра.

Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларына карата граждан хезмәткәрләре вазыйфаи регламентларында министр карары буенча конкрет белгечлеккә

(әзерлек юнәлешенә) карата квалификация таләпләре билгеләнергә мөмкин.

4.3. Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның квалификация таләпләренә турын килүен бәяләү өчен конкурс процедуралары барышында федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына каршы килми торган бәяләү ысуллары кулланылырга мөмкин.

4.4. Конкурс ике этапта уздырыла.

4.5. Беренче этапта Министрлыкның кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс уздыру турында мәгълүмат әзерләүне һәм аны Министрлык һәм Федераль мәгълүмат системасы сайтларында урнаштыруны, анда түбәндәгеләр була: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйвасы) исеме, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) кандидатлар тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты, күрсәтелгән документларны кабул итүнең соңгы срогы, конкурс уздыруның күздә тотыла торган датасы, аны уздыру урыны һәм тәртибе, бәяләү ысуллары турында белешмәләр, граждан хезмәткәре вазыйфаи регламентының вазыйфаи бурычлар, хокуклар һәм вазыйфаи бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен җаваплылык каралган нигезләмәләре, граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләре һәм уңышлары, Федераль мәгълүмат системасында урнаштырылган алшарт квалификация тестына сылтама, башка мәгълүмати материаллар;

кандидатлар тапшырган документларны тикшерүне;

гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен (һөнәри белем дәрәҗәсе, граждан хезмәте (башка төр дәүләт хезмәте) стажы яисә белгечлеге буенча тәҗрибә (эш) стажы, әзерлек юнәлеше, вазыйфаи бурычларны башкару өчен кирәкле һөнәри белемнәр һәм күнекмәләр) тикшерүне.

4.6. Кандидат үзенең һөнәри дәрәҗәсен мөстәкыйль бәяләү өчен, конкурс кысаларыннан тыш, алдан квалификация тестын узарга мөмкин, бу хакта конкурс белдерүендә күрсәтелә.

Алдан уздырыла торган тестка кандидатларның Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү дәрәҗәсен, Россия Федерациясе Конституциясен, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын белү, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге белемнәре һәм күнекмәләре дәрәҗәсен бәяләү өчен биремнәр кертелә.

Алдан уздырыла торган Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла, кандидатларга аны узу мөмкинлеге бушлай бирелә.

Кандидатның алдан тест узу нәтиҗәләре конкурс комиссиясе игътибарына алынмый һәм конкурста катнашу өчен аның документларын алудан баш тарту өчен нигез була алмый.

4.7. Тикшерү барышында федераль законнар һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары нигезендә гражданның граждан хезмәтенә керүенә тоткарлык ясый торган шартлар ачыкланганда, аңа конкурста катнашуга кертмәү сәбәпләре турында министр тарафыннан язма рәвештә хәбәр ителә. Граждан конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә җибәргән очракта, аңа конкурста катнашуга кертмәү сәбәпләре турындагы хәбәрнамә, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә.

4.8. Конкурста катнашуга кертелмәгән, вакантлы вазыйфага дәгъва кылучы Россия Федерациясе законнары нигезендә бу карарга карата шикаять бирергә хокуклы.

4.9. Конкурсның беренче этабы тәмамлану шарты булып, Министрлыкта граждан хезмәтенең бер вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасына) тиешле квалификация таләпләренә туры килә торган кимендә ике кандидат калу кирәк, бу кандидатларны алга таба сайлауны гамәлгә ашыру мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаган яисә вазыйфага карата квалификация таләпләрен канәгатьләндерә торган бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип танылa. Бу очракта бердәнбер кандидатка тиешле санда кандидатлар булмау сәбәпле конкурсның узмаган дип танылуы турында язма рәвештә хәбәр ителә.

4.10. Конкурсның беренче этабы тәмамлангач, министр конкурсның икенче этабын уздыру датасы (әмма катнашу өчен документлар алу тәмамланган көннән соң 30 календарь көннән дә соңга калмыча), вакыты һәм урыны турында карар кабул итә. Дәүләт серен яисә закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләргә керү рөхсәт ителә торган очракта, конкурсның икенче этабын уздыру срогын министр билгели.

Кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башлануга кадәр 15 календарь көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның һәм Федераль мәгълүмат системасының рәсми сайтларында аны уздыруның датасы, урыны һәм вакыты турында мәгълүмат, конкурта катнашуга кертелгән кандидатлар исемлеген урнаштыра һәм кандидатларга язма рәвештә тиешле хәбәрнамәләрне җибәрә, конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә җибәргән кандидатларга хәбәрнамәне, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә.

4.11. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр башкарыла:

кандидатлар турындагы мәгълүмат «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» (алга таба – Кадрларның бердәм мәгълүмат системасы) Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелә;

кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларына конкурс комиссиясе биргән бәяләү;

Министрлыкта гражданхезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервына) конкурста җиңүчене билгеләү турында конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул итү;

конкурс нәтиҗәләрен Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында рәсмиләштерү;

конкурс нәтиҗәләрен Федераль мәгълүмат системасында бастырып чыгару.

4.12. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар тапшырган белем турындагы документлар, граждан хезмәтендә яисә башка дәүләт хезмәтендә эшләве, бүтән хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы буенча, шулай ук тест, кара-каршы әңгәмә кору, эссе язу кебек ысулларны бәяләү процедуралары нәтиҗәләре нигезендә бәяли. Үзләренә карата конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркемнәренә һәм категорияләренә бәйле рәвештә, төрле ысуллар куланылырга мөмкин. Ә тест уздыру һәм кандидат белән кара-каршы әңгәмә кору барлык кандидатлар өчен катгый ысуллар булып торалар.

4.12.1. Язма эш (эссе) (алга таба - Эш) өчен граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) вазыйфаи бурычлардан, шулай ук бу вазыйфаларны билү өчен квалификация таләпәреннән чыгып төзелгән сораулар (биремнәр) кулланыла.

Конкурс комиссиясе утырышына кадәр кимендә 10 календарь көннән дә соңга калмыйча, кандидатларга Эш сораулары (биремнәр) җибәрелә, алар конкурс уздырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан яисә кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчәләр җитәкчеләре тарафыннан билгеләнә һәм конкурс комиссиясе рәисе белән килештерелә.

Эш түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

язма эш (эссе) күләме - 2 биттән 3 биткә кадәр;

шрифт - Times New Roman, размеры - 14, бер интервал аша.

Эшне кандидатлар конкурс комиссиясе секретарена конкурс комиссиясе утырышын уздыруга кадәр кимендә 5 календарь көннән дә соңга калмыйча тапшыралар.

Эшне бәяләү нәтиҗәләре Министрлыкның Эш темасын билгеләгән структур бүлекчәсе җитәкчесе тарафыннан рәсмиләштерелә, ул түбәндәге критерийлар буенча чыгарылган йомгаклау баллы күрсәтелгән кыскача белешмә рәвешендә була:

| №<br>т/с | Критерийлар | Бәя |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Билгеләнгән рәсмиләштерү таләпләренә туры килү | 0 - 1, биредә:<br>0 – туры килми,<br>1 – туры килә |
| 2 | Теманы ачу | 0 - 1, биредә:<br>0 – ачылмаган,<br>1 - ачылган |
| 3 | Аналититик сәләт, фикерләү логикасы | 0 - 1, биредә:<br>0 – түбән дәрәҗә,<br>1 – җитәрлек дәрәҗә |
| 4 | Бирелгән тема буенча тапшырылган тәкъдимнәрнең нигезле булуы һәм практикада гамәлгә ашырылуы | 0 - 5, биредә:<br>0 – гамәлгә ашыру мөмкин түгел,<br>5 – бүгенге шартларда практикада гамәлгә ашыру дәрәҗәсе югары |
| 5 | Хокукый һәм лингвистик белем | 0 - 2, биредә:<br>0 – түбән дәрәҗә,<br>1 – мөмкин дәрәҗә,<br>2 – югары дәрәҗә |

Эшне бәяләгәндә иң югары балл 10 балл була.

Объектив бәяләүне уздыру максатларында кандидатлар эзерләгән Эшләрнең исемсез (аноним) булуы тәэмин ителә.

4.12.2. Тест уздыру аша кандидатларның Министрлыкта граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү һәм аларны кадрлар резервына кертү өчен Россия Федерациясе дәүләт телен (рус телен) белү дәрәҗәсе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре нигезләрен белү, дәүләт хезмәте турында һәм коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын белү дәрәҗәсе, мәгълүмат-коммуникация технологияләре өлкәсендәге белем һәм күнекмәләре, шулай ук һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә бәйле белем һәм күнекмәләре бәяләнә.

Тестны оештыру Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында Министрлыктан кергән заявкалар нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан башкарыла.

Тест уздыруга заявка Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында конкурс комиссиясе утырышына кадәр ике атнадан да соңга калмыйча кадрлар хезмәте тарафыннан тутырыла.

Тест уздыру Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 11 декабрендәге ПУ-1192 номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте

вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарга тест уздыруны оештыру мәсьәләләре» Указы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан расланган тест уздыру методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тест нәтиҗәләре Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында чагылдырыла. Конкурс комиссиясе секретаре нәтиҗәләрне, 10 баллы системага күчереп, кыскача белешмә рәвешендә бирә.

4.12.3. Кандидатлар белән белән кара-каршы әңгәмә кору конкурс комиссиясе тарафыннан башкарыла.

Кара-каршы әңгәмә кору кысаларында кандидатның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүгә юнәлдерелгән сораулар бирелә.

Шул максатларда, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) вазыйфаи бурычларны исәпкә алып, граждан хезмәтенең һәр вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча) сораулар исемлеге төзелә. Сораулар исемлеге комиссия утырышына, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе яисә кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе белән берлектә, кадрлар бүлеге тарафыннан әзерләнә.

Алдан кара-каршы әңгәмә кору граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе яисә кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчә җитәкчесе тарафыннан үткәрелергә мөмкин.

Конкурс комиссиясе утырышына кадәр алдан кара-каршы әңгәмә кору үткәрелгән очракта, аны үткәргән зат конкурс комиссиясе утырышы барышында телдән нотык рәвешендә кара-каршы әңгәмә нәтиҗәләре турында конкурс комиссиясенә мәгълүмат бирә.

Конкурс комиссиясе утырышын үткәргәндә министр карары буенча тиешле конкурс процедураларын уздыруның видео- һәм (яисә) аудиоязмалары алып барыла.

Кандидат белән кара-каршы әңгәмә тәмамлангач, конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы әлеге Нигезләмәнең 4 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча тутырыла торган конкурс бюллетененә кандидатны бәяләү нәтиҗәсен язып куя.

Әңгәмә нәтиҗәләрен бәяләгәндә иң югары балл 10 балл була.

4.13. Кандидатның йомгаклау баллы кара-каршы әңгәмә нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кандидатка куелган уртача арифметик баллар һәм кандидатның тест сорауларын һәм башка конкурс биремнәрен үтәү йомгаклары буенча җыйган баллары суммасы буларак билгеләнә.

Кандидатларның йомгаклау балларын чыгару нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе секретаре кандидатларның рейтингын төзи.

4.14. Конкурс комиссиясенең карары конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып санала, ул әлеге Нигезләмәнең 2.10 пунктында күрсәтелгән конкурс комиссиясе утырышының карар бланкында яисә беркетмә бланкында тутырыла.

4.15. Әгәр конкурс уздыру нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча (кадрлар резервының граждан хезмәте вазыйфасына кертү буенча) кирәкле барлык таләпләргә туры килә торган кандидатлар табылмаса, конкурс комиссиясе конкурста җиңүче булмады дигән карар кабул итә.

4.16. Конкурс комиссиясе шулай ук граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче дип танылмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары буенча югары бәя алган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында тәкъдим характерындагы карар кабул итәргә хокуклы.

Кандидатны граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы кергән төркемдә үк граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен кадрлар резервына кертү турында министр боерыгы кандидат ризалыгы белән чыгарыла, ул язма рәвештә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә рәсмиләштерелә.

Граждан хезмәткәрен (гражданны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү министр боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.17. Конкурс нәтиҗәләре турында хәбәрнамәләр ул тәмамланганнан соң 7 көн эчендә язма рәвештә кандидатларга җибәрелә, конкурста катнашу өчен документларын электрон рәвештә җибәргән кандидатларга хәбәрнамә, Федераль мәгълүмат системасыннан файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шул ук срокта Министрлыкның рәсми сайтында, Федераль мәгълүмат системасында һәм Кадрларның бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы Авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгында дәүләт
граждан хезмәтенең
вакантлы вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына кертүгә)
конкурс уздыру турында
нигезләмәгә
**1 нче кушымта**

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы азыйфасын биләүгә конкурс уздыру йомгаклары буенча конкурс комиссиясе КАРАРЫ**

«__» _________ 20__ ел
конкурс уздыру датасы

Конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясенең ________ әгъзасыннан _________ катнашты:

Комиссия рәисе: ________________________________________________
фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе секретаре: ____________________________________
фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе әгъзалары: ______________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
фамилиясе, инициаллары

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздырылды
_________________________________________________________________
вазыйфаның, структур бүлекчәнең исеме
_________________________________________________________________

Кандидатларның рейтингта бәяләү нәтиҗәләре:

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Йомгаклау баллары | Рейтингтагы урыны (кимү бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

Конкурста җиңүчене билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:
(барлык кандидатлар буенча тутырыла)

| | | | |
|---|---|---|---|
| Рейтингта беренче урынны алган кандидатның Ф.И.Ат. Ис. <*> | | | |
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «каршы» | «тоткарланучылар» |
| | | | |
| | | | |
| Барысы: | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Рейтингта икенче урынны алган кандидатның Ф.И.Ат. Ис. <*> | | | |
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «каршы» | «тоткарланучылар» |
| | | | |
| | | | |
| Барысы: | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Рейтингта өченче урынны алган кандидатның Ф.И.Ат. Ис. <*> | | | |
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «каршы» | «тоткарланучылар» |
| | | | |
| | | | |
| Барысы: | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә карата комментарийлар (кирәк булса)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Конкурс комиссиясе тавыш бирү йомгаклары буенча

______________________________________________________________________

Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме <*>

конкурста җиңүче дип таный.

Конкурс комиссиясе тавыш бирү йомгаклары буенча дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар резервына түбәндәге кандидатларны кертергә тәкъдим итә:

______________________________________________________________________

кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме <*>

______________________________________________________________________

Комиссия рәисе: _______________________________________________

имза, фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе секретаре: _______________________________________

имза, фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе әгъзалары:________________________________________

______________________________________________________________________

имза, фамилиясе, инициаллары

____________________________________________________________________

имза, фамилиясе, инициаллары

--------------------------------

<*> Атасының исеме булган очракта күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турында нигезләмәгә
**2 нче кушымта**

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар резервына кертү буенча конкурс комиссиясе утырышы**
**БЕРКЕТМӘСЕ**

«__» __________ 20__ ел
конкурс уздыру датасы

Конкурс комиссиясе утырышында конкурс комиссиясенең ________ әгъзасыннан _________ катнашты:

Комиссия рәисе:______________________________________
фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе секретаре: ___________________________
фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе әгъзалары: ___________________________
фамилиясе, инициаллары

______________________________________________________

______________________________________________________
фамилиясе, инициаллары

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар резервына кертү буенча конкурс уздырылды

______________________________________________________
вазыйфалар төркеменең исеме

Кандидатларның рейтингта бәяләү нәтиҗәләре:

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Йомгаклау баллары | Рейтингтагы урыны (кимү бару тәртибендә) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |

Дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар резервына кертү өчен кандидатны (кандидатларны) билгеләү буенча тавыш бирү нәтиҗәләре:

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| Рейтингта беренче урынны алган кандидатның Ф.И.Ат. Ис. <*> | | | |
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «каршы» | «тоткарланучылар» |
| | | | |
| | | | |
| Барысы: | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| Рейтингта икенче урынны алган кандидатның Ф.И.Ат. Ис. <*> | | | |
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «каршы» | «тоткарланучылар» |
| | | | |
| | | | |
| Барысы: | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | |
| Рейтингта өченче урынны алган кандидатның Ф.И.Ат. Ис. <*> | | | |
| Конкурс комиссиясе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Тавыш бирү | | |
| | «хуплыйм» | «каршы» | «тоткарланучылар» |
| | | | |
| | | | |
| Барысы: | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәләренә карата комментарийлар (кирәк булса)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Конкурс комиссиясе тавыш бирү йомгаклары буенча

______________________________________________________________________

кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме <*>

кадрлар резервына кертү өчен билгели.

Комиссия рәисе: ______________________________________________

имза, фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе секретаре: ______________________________________

имза, фамилиясе, инициаллары

Конкурс комиссиясе әгъзалары:______________________________________

имза, фамилиясе, инициаллары

______________________________________________________________________

имза, фамилиясе, инициаллары

--------------------------------

<*> Атасының исеме булган очракта күрсәтелә.

Татарстан Республикасы Авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгында дәүләт
граждан хезмәтенең
вакантлы вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына кертүгә)
конкурс уздыру турында
нигезләмәгә
**3 нче кушымта**

Кемгә: Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры

________________________________________

фамилиясе, инициаллары

Кемнән:

________________________________________

фамилиясе, инициаллары

________________________________________

________________________________________

фактта яшәү адресы

________________________________________

________________________________________

телефон

гариза

Мине Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең түбәндәге вазыйфасын биләү өчен Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм:

________________________________________________________________________

________________________________________________________________________

(вазыйфаның һәм бүлекчәнең исеме)

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздыру турындагы

нигезләмә, шулай ук вакантлы вазыйфаны биләү өчен куела торган квалификация таләпләре белән таныштым.

«Шәхси белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә үземнең шәхси белешмәләрнең тикшерелүенә риза.

Конкурсны уздыру датасы һәм урыны турында күрсәтелгән мобиль телефон номерына СМС-хәбәр аша хәбәр бирелүгә риза.

Гаризага түбәндәгеләрне өстәп тапшырам:

____________________________________________________________

(өстәп бирелә торган документлар исемлеге)

____________________________________________________________

____________________________________________________________

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | __________________ | ______________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаның киңәйтелгән язылышы) |

Татарстан Республикасы Авыл
хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгында дәүләт
граждан хезмәтенең
вакантлы вазыйфасын биләүгә
(кадрлар резервына кертүгә)
конкурс уздыру турында
нигезләмәгә
**4 нче кушымта**

Конкурс бюллетене
«__» ___________ 20__ ел

_______________________________________________
биләү өчен конкурс уздырыла торган вазыйфаның исеме
_______________________________________________
яисә кадрлар резервына кертү өчен конкурс уздырыла торган
вазыйфалар төркеме исеме
_______________________________________________

Кара-каршы әңгәмә нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзасы тарафыннан кандидатларга бирелә торган баллар (иң югары балл 10 балл була).

| Кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме <*> | Балл | Куелган баллны кыскача дәлилләү (кирәк булса) |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

_____________________________ _____________________________
Конкурс комиссисе әгъзасының фамилиясе, исеме, атасының исеме — имза

--------------------------------

<*> Атасының исеме булган очракта күрсәтелә.